**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы, 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

“ 06 ” август 2024 ел № 370

**Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты җитәкчесенең 2024 елның 01 мартындагы 164 номерлы карары белән расланган "2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру" муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында**

1. Әтнә муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү, коррупциячел хокук бозуларны кисәтүгә ярдәм итә торган чараларның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы “2015-2025 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру дәүләт программасын раслау турында” карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 31 маендагы 390 номерлы “Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында” карарын кабул ителүгә бәйле рәвештә, Әтнә районы Татарстан Республикасы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының 2024 елның 01 мартындагы 164 номерлы "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында 2024-2026 елларга коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру муниципаль программасын раслау турында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карар исемендә "2024-2026" саннарын “2024-2027" саннарына алмаштырырга;

1.2 карар преамбуласында “2015-2025 елларга” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3 карарның 1 пунктында "2024-2026" саннарын “2024-2027" саннарына алмаштырырга”;

1.4 карарның 1 нче кушымтасында исемдә һәм алга таба текст буенча "2024-2026" саннарын "2024-2027" саннарына алмаштырырга”;

1.5 программа паспортында “Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары” юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>Программаны финанслау кулэме һәм чыганаклары</td>
<td>
2024-2027 елларга Программаны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауның гомуми күләме 290,00 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>
(мең сумнарда)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>ТР Әтнә муниципаль районының җирле бюджеты акчалары</th></tr>
<tr><td>2024</td><td>60,0</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>70,0</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>80,0</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>80,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>290,0</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш
</td>
</tr>
</table>

1.6 Программа паспортында “Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләрен (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларын) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен” юлында “2026 ел ахырына” сүзләрен “2027 ел ахырына”сүзләренә алмаштырырга.

1.7 V бүлектә “2026 елга” сүзләрен “2027 елга” сүзләренә алмаштырырга.

1.8 Коррупциягә каршы муниципаль программа бурычлары, чаралары һәм индикаторлары исемлеген 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әтнә муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясенә йөкләргә.

Җитәкчесе А.Ф.Каюмов